РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БУИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

02.02.2024 Буа шәһәре № 14 Бк/к

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының «Арктика» спорт мәктәбе» МБУ тарафыннан күрсәтелә торган өстәмә түләүле хезмәтләргә тарифларны раслау турында» 2022 елның 20 апрелендәге 105/Бк/к номерлы карарына

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131 – ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә ТР Буа муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының «Арктика» спорт мәктәбе» МБУ тарафыннан күрсәтелә торган өстәмә түләүле хезмәтләргә тарифларны раслау турында» 2022 елның 20 апрелендәге 105/Бк/к номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының «Арктика» спорт мәктәбе» муниципаль бюджет учреждениесе» исемен ТР Буа муниципаль районы Башкарма комитетының 2023 елның 22 мартындагы 70/Бк/к «Спорт мәктәпләренең исемен үзгәртү турында» номерлы карары нигезендә «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының «Арктика» спорт мәктәбе» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесе исеменә алыштырырга.

1.2. Карарның кушымтасын кушымта буенча яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Әлеге карар имзаланган көннән үз көченә керә һәм Интернет мәгълүмат – телекоммуникация челтәренең Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында урнаштырылырга тиеш http://buinsk.tatarstan.ru.

3. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны Буа муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Сәдретдинова Лилия Нәзим кызына йөкләргә.

Җитәкче Л.Р. Шакирҗанов

кушымта

*«Арктика» спорт мәктәбе муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесе*

Боз сарае

| № т/б | Хезмәтләр | Өлкәннәр өчен бәя | 16 яшькә кадәрге балалар өчен бәя |
|---|---|---|---|
| 1 | Кичке, бәйрәм һәм ял көннәрендә массакүләм шууларга керү:<br><br>үз тимераяклары белән: | 200 сум<br><br>100 сум. | 80 сум<br><br>50 сум. |
| 2 | Бозны бер сәгатькә арендага алган оешмалар өчен тимераяклар алып тору:<br>үз тимераяклары белән: | 100 сум<br><br>- | 60 сум<br><br>- |
| 3 | Көндезге сәгать 15.00 гә кадәр (якшәмбедән тыш) мәктәп укучылары өчен тимераяклар алып тору:<br><br>үз тимераяклары белән: | -<br><br>- | 50 сум.<br><br>25 сум. |
| 4 | Тимераяклар кайрау | 200 сум | 100 сум<br>50 сум – ( «Арктика» спорт мәктәбендә шөгыльләнүчеләр өчен ) |
| 5 | 1 сәгатькә бозны арендалау – чит шәһәрләр өчен | 4000 сум. | |
| 6 | 1 сәгатькә бозны арендалау – район һәм шәһәр халкы өчен | 3750 сум. | |
| 7 | Хоккей матчы уздыру өчен бозны арендалау | 4000 сум (командадан) | |
| 8 | «Арктика» спорт мәктәбендә шөгыльләнүчеләр өчен өстәмә дәресләр өчен | 2000 сум | |

Ачык шугалак

| № т/б | Хезмәтләр | Өлкәннәр өчен бәя | 16 яшькә кадәрге балалар өчен |
|---|---|---|---|
| 1 | Тимераяклар алып тору | 100 сум | 50 сум. |
| 2 | Үз тимераякларың белән керү | түләүсез | түләүсез |

Украинада махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзалары өчен массакүләм шуугa йөрү бушлай.

«Арктика» спорт мәктәбе кунакханәсе

| Уңайлылык | Урыннар | 1 урын бәясе (сум.) |
|---|---|---|
| Стандарт | 2-3 урынлы | Ярышларда катнашу өчен 18 яшькә кадәрге спортчылар өчен-550 сум.<br>18 яшье тулганнарны да кертеп гражданнар өчен -650 сум |
| Стандарт (яхшыртылган) | 1 урынлы | 1000 сум |

Яшәү бәясенә керүче хезмәтләр исемлеге:

1.Сөлгеләрне алыштырып (көн саен) бүлмәне чистарту
2. Бүлмәдәге җиһазларны куллану
3. Билгеләнгән вакытка уяту
4. Аптечка бирү һәм ашыгыч медицина ярдәме чакыру
5. Такси чакыру

Башка өстәмә хезмәтләр

| Хезмәт төрләре | тәүлек/тапкыр | Бәясе |
|---|---|---|
| Кер юу | 1 | 200 сум |

Башкаручы һәм заказчы арасындагы исәп-хисаплар акчалата формада яки заказчы тарафыннан башкаручының исәп-хисап счетына акча күчерү юлы белән башкарыла.